ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«_17_» _декабрь_ 2019г.** **№ _1107_**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шурабаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы - «Байкал башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» эшчәнлеген туктатып тору турында**

Оптимальләштерү процедураларын уздыруга һәм матди-техник, кадрлар, идарә ресурсларын нәтиҗәле файдалану, мәгариф учреждениеләренең финанс чыгымнарын оптимальләштерү максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шурабаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Байкал башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» эшчәнлеген туктатып торырга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә (Р.Д. Мөхәмәдияров):

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шурабаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Байкал башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» укучыларын алга таба укытуга бәйле оештыру чараларын үткәрергә;

- эштән азат ителгән хезмәткәрләрне хезмәт законнарына ярашлы рәвештә эшкә урнаштыру мәсьәләләрен хәл итәргә;

-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шурабаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы “Байкал башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе” милкен һәм бинасын саклау өчен җаваплылыкны мәктәп директоры З.И. Хәйруллинга йөкләргә.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә (Ф.Р. Исмәгыйлев), Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә (Р.Д. Мөхәмәдияров) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шурабаш төп гомуми белем бирү

мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең штат расписаниесенә тиешле үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http//arsk/tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин